# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан 2003 елның 11 сентябрендә кабул ителде

**1 статья**. «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11-12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, № 11; 2001, № 7-8) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1. 1 статьяда «өстенлеген» сүзе алдыннан «Татарстан Республикасының хокукый системасында» сүзләрен өстәргә.

2. 3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды вәкаләтләре

1. Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгеләрнең конституциячеллеге турындагы эшләрне карый:

1) Татарстан Республикасы законнарының;

2) Татарстан Республикасы Президенты һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башка органнары норматив хокукый актларының;

3) җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының;

4) Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышлары турындагы килешүләрнең.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Конституциясенә аңлатма бирә.

3. Конституция суды түбәндәгеләрнең компетенциясе турындагы бәхәсләрне карый:

1) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасындагы;

2) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары арасындагы;

3) жирле үзидарә органнары арасындагы.

4. Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Президенты гамәлләренен һәм карарларының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве турында бәяләмә бирә.

5. Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга шикаятьләр буенча һәм суд соравы буенча Татарстан Республикасы законының яисә аның аерым нигезләмәләренен, Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинеты, шулай ук жирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларының конституциячеллеген тикшерә.

6. Конституциячел түгел дип танылган актлар яисә аларның аерым нигезләмәләре Татарстан Республикасы Конституция суды карары рәсми басылып чыккан көннән үз көчләрен югалталар.

7. Татарстан Республикасы Конституция судының үз вәкаләтләре чикләрендә кабул иткән карары катгый була, ул башка суд тарафыннан кабат карала алмый.

8. Татарстан Республикасы Конституциясе нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды Татарстан Республикасы Дәүләт Советында үз карамагындагы мәсьәләләр буенча закон чыгару инициативасы хокукына ия.

9. Татарстан Республикасы Конституция суды бары тик хокук мәсьәләләрен генә хәл итә һәм конституциячел суд эшләрен башкарганда башка судлар яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең бүтән органнары компетенциясенә кергән барлык очракларда факттагы хәлләрне ачыклаудан һәм тикшеренүдән тыелып кала.

10. Татарстан Республикасы Конституция суды үзенен эчке эшчәнлеге мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Регламентын кабул итә.».

3. 4 статьяның беренче өлешендәге икенче абзацында «раслана» сүзен «билгеләнә» сүзенә алмаштырырга.

4. 7 статьяның икенче өлешендә «республика» сүзен төшереп калдырырга, «Республикасының» сүзен «Республика» дип язарга.

5. 8 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы урынына кандидатка куелучы таләпләр

Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы булып Татарстан Республикасындагы, 25 тән яшьрәк булмаган, югары юридик белемле, юридик һөнәр буенча кимендә биш ел эш стажы булган граждан сайлана ала.».

Исп., тел.
C:\Leisan\Perevod\zakon\2003\konst.doc

6. 9 статьяның беренче өлешендә «тигез санда» сүзләрен «бертигез санда» сүзләренә алмаштырырга.

7. 12 статьяның беренче һәм икенче өлешләрендә «җитмеш яшькә», «җитмеш яшь» сүзләрен «алтмыш биш яшькә», «алтмыш биш яшь» сүзләренә алмаштырырга.

8. 15 статьяда «Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә» сүзләрен «федераль закон нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

9. 19 статьяда:

статьяның исемендә һәм текстта «матди» сүзеннән соң «һәм социаль» сүзләрен өстәргә;

статья текстында «гарантияләре» сүзеннән соң «тиешле категория судьялар өчен Россия Федерациясендә судьялар статусы турында федераль законнарда, шулай ук» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле яна җөмлә өстәргә: «Бу чакта Татарстан Республикасы Конституция суды Рәисенең хезмәт оклады күләме Татарстан Республикасы Югары суды Рәисенең хезмәт окладыннан түбәнрәк булмаган күләмдә билгеләнә.».

10. 20 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«20 статья. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләрен туктатып тору

1. Судьяның вәкаләтләре Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе карары белән түбәндәге нигезләрнең берәрсе булганда туктатып торыла:

1) Татарстан Республикасы Конституция суды судьясын законлы көченә кергән суд карары белән хәбәрсез югалган дип танылганда;

2) Татарстан Республикасы Конституция суды судьясына карата җинаять эше кузгатылганда йә аны башка җинаять эше буенча гаепләнүче буларак җавапка тартканда;

3) Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы Россия Федерациясе Дәүләт Думасы яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлыгына кандидат буларак сайлау алды кампаниясендә катнашканда;

4) Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты, Федерация Советы әгъзасы яисә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты булып сайланганда.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләрен туктатып тору, аны сак астына алу кисәтү чарасы буларак сайланган очрактан гайре, судьяга түләүләрне туктатуга китерми, әгәр ул хәбәрсез

югалган дип танылса, -- анын гаиләсенә эш хакын түләүне туктатуга яисә анын күләмен киметүгә китерми. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләрен туктатып тору, аны сак астына алу кисәтү чарасы буларак сайланган очрактан гайре, судьяны матди һәм социаль тәэмин итүнең башка төрләре дәрәҗәсен төшерүгә китерми һәм аны законнарда билгеләнгән кагылгысызлык гарантиясеннән мәхрүм итми.

3. Судьяның вәкаләтләрен торгызу турындагы карарны анын вәкаләтләрен туктатып торган Татарстан Республикасы судьяларының квалификация коллегиясе кабул итә.».

11. 21 статьяда:

беренче һәм икенче өлешләрне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының вәкаләтләре түбәндәге нигезләр буенча туктатыла:

1) судьяның отставкага китү турындагы язмача гаризасы булганда;

2) сәламәтлеге аркасында яисә башка мөһим сәбәпләр буенча судья вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга сәләтсез булганда;

3) судьяның башка эшкә күчүгә бәйле яисә бүтән сәбәпләр буенча үз вәкаләтләрен туктату турындагы язмача гаризасы булганда;

4) судьяның вәкаләтләре чоры тәмамланганда;

5) Россия Федерациясе гражданлыгы туктатылганда;

6) судья вазыйфасына туры килми торган эшчәнлек белән шөгыльләнгәндә;

7) судьяга карата судның гаепләү карары законлы көченә кергәндә йә аңа карата медицина характерындагы мәҗбүри чараларны куллану турындагы суд карары үз көченә кергәндә;

8) судьяның хезмәткә сәләте чикләнгәнлеге турында йә аны хезмәткә сәләтсез дип тану турында суд карары законлы көченә кергәндә;

9) судья вафат булганда яисә аны вафат булган дип игълан итү турында суд карары законлы көченә кергәндә.

10) судья урынында булунын иң чик яшенә житкәндә.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды судьясының вәкаләтләре әлеге статьяның беренче өлешендәге 1-3, 5-9 пунктларында каралган нигезләр буенча вакытыннан алда туктатылырга мөмкин»;

түбәндәге эчтәлектә яңа өченче өлеш өстәргә:

«3. Татарстан Республикасы судьялары квалификация коллегиясенең Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы вәкаләтләрен туктату турындагы карары юкка чыгарылган яисә судның аның турында булган гаепләү карары йә әлеге статьяның беренче өлешендәге 7 пунктында күрсәтелгән суд карары юкка чыгарылган очракта, судья, аңа тиешле эш хакын түләп, элеккеге эш урынына кире кайтарылырга тиеш.»;

өченче, дүртенче өлешләрне дүртенче, бишенче өлешләр дип санарга.

12. 22 статьяда:

беренче өлештә «беренче өлешенен 2, 3 һәм 9 пунктларында һәм икенче өлешендә» сүзләрен «беренче өлешенен 1, 2, 4, 8 һәм 10 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

икенче өлештә «Татарстан Республикасы законнары нигезендә» сүзләрен «законнар нигезендә» сүзләренә алмаштырырга; өченче өлештә «Татарстан Республикасы законнарында» сүзләрен «законнарда» сүзенә алмаштырырга.

13. 29 статьяда «судьялары,» сүзеннән соң «Татарстан Республикасының хокукый системасында» сүзләрен өстәргә.

14. 32 статьяда:

икенче җөмләне төшереп калдырырга;

өченче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Конституция суды карарлары халыкка игълан ителә.».

15. 34 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Суд эше алып барыла торган телне белмәгән эштә катнашучы затларга туган телендә йә ирекле сайлап алынган теләсә нинди аралашу телендә чыгыш ясау һәм аңлатмалар бирү, шулай ук тәрҗемәче хезмәтләреннән файдалану хокукы тәэмин ителә.».

16. 39 статьяның икенче өлешендәге 1 пунктында «үз көченә кермәгән халыкара шартнамәсенең» сүзләрен «халыкара һәм тышкы икътисадый бәйләнешләр турындагы үз көченә кермәгән килешүнең» сүзләренә алмаштырырга.

17. 40 статьяның икенче өлешендәге 4 пунктында, 54 статьяның беренче өлешендәге 3 пунктында «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга, «органының» сүзен «органның» дип, «органнары» сүзен «органнар» дип язарга.

18. 41 статьяның өченче өлешендә «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга, «органнары» сүзен «органнар» сүзенә алмаштырырга.

19. 43 статьяда:

икенче өлештә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүче әлеге мәсьәлә буенча Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карар кабул итүне таләп итәргә хокуклы.»;

дүртенче өлештә «дәүләт» сүзен төшереп калдырырга, «органнарына» яисә оешмаларына» сүзләрен «органнарга һәм оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга.

Исп., тел.
C:\Leisan\Perevod\zakon\2003\konst.doc

20. 45 статьяның өченче өлешендә «халыкара шартнамәсенең» сүзләрен «халыкара һәм тышкы икътисадый бәйләнешләр турындагы килешүенең» сүзләренә алмаштырырга.

21. 50 статьяга түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Һәр эшне карау аерым утырыш предметын тәшкил итә. Татарстан Республикасы Конституция суды бер үк предметка кагылышлы мөрәҗәгатьләр буенча эшләрне карауны бер эштә берләштерергә мөмкин.».

22. 52 статьяның өченче өлешендә «республика» сүзен төшереп калдырырга.

23. 54 статьяның икенче өлешендә «халык депутаты» сүзләрен «Дәүләт Советы депутаты» сүзләренә алмаштырырга.

24. 55 статьяда:

икенче өлешне төшереп калдырырга;

өченче-бишенче өлешләрне икенче-дүртенче өлешләр дип санарга.

25. 59 статьяның икенче өлешендәге беренче абзацында «дәүләт органнары,» сүзләреннән соң «җирле үзидарә органнары,» сүзләрен өстәргә.

26. 63 статьяда «шартнамә» сүзен «килешү» сүзенә алмаштырырга.

27. 67 статьяның өченче өлешендә «шартнамәнең» сүзен «килешүнең» сүзенә алмаштырырга.

28. 68 статьяда:

түбәндәге эчтәлекле яңа дүртенче өлеш өстәргә:

«4. Әгәр Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан эш каралганда, аның карары белән Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килми йә каралган нормалары аның карарында билгеләнгән конституциячел-хокукый мәгънәсенә туры килми дип танылган нормаларны китереп чыгаручы норматив-хокукый актлар яисә аның аерым нигезләмәләре ачыкланса, Татарстан Республикасы Конституция суды аларны Татарстан Республикасы Конституциясенә туры китерүнең вакытын һәм тәртибен билгеләргә хокуклы.»;

дүртенче һәм бишенче өлешләрне бишенче һәм алтынчы өлешләр дип санарга.

29. 71 статьяда:

беренче өлештә «Югары арбитраж» сүзләрен «Арбитраж» сүзенә алмаштырырга;

икенче өлештә «дәүләт органнарына» сүзләреннән соң «, жирле үзидарә органнарына» сүзләрен өстәргә.

30. 79 статьяны төшереп калдырырга.

31. IX бүлекнең исемендә «законнарының һәм башка норматив хокукый актларының» сүзләре алдындагы «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга, әлеге сүзләрне «законнарның һәм башка норматив хокукый актларның» дип язарга.

32. 81 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«81 статья. Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукы

Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы законнарының һәм әлеге Законның 3 статьясындагы беренче өлешенең 1, 2 һәм 3 пунктларында күрсәтелгән башка норматив хокукый актларның конституциячеллеген тикшерүне сорап, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның Президиумы һәм комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санынның биштән бере, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм жирле үзидарә органнары мөрәҗәгать итәргә хокуклы.».

33. 82 статьяда «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының» сүзләреннән соң «, жирле үзидарә органнарының» сүзләрен өстәргә.

34. 83 статьяда:
беренче һәм икенче өлешләрдә «Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның» сүзләренә алмаштырырга;
беренче өлешнең 5 пунктында «һәм идарәсе» сүзләрен «органнары һәм жирле үзидарә» сүзләренә алмаштырырга.

35. 84 статьяның барлык тексты буенча «Татарстан Республикасы законының яисә башка норматив хокукый актының» сүзләрен «Татарстан Республикасы законының яисә башка норматив хокукый актның» сүзләренә алмаштырырга.

36. X бүлекнең исемендә, 87, 88 статьяларда «халыкара шартнамә» сүзләрен тиешле саннарда һәм килешләрдә «халыкара һәм тышкы икътисадый бәйләнешләр турындагы килешү» сүзләренә алмаштырырга; 87

статьяның 2 һәм 3 пунктларында «шартнамә», «шартнамәләрне» сүзләрен «килешү», «килешүләрне» сүзләренә алмаштырырга.

37. 85 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«85 статья. Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать итү хокукы

Татарстан Республикасы Конституция судына, үз көченә кермәгән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышлар турында килешүләрнең конституциячеллеген тикшерүне сорап, Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, аның Президиумы һәм комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән саныннан биштән бере, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм җирле үзидарә органнары мөрәҗәгать итәргә хокуклы.».

38. 86 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«86 статья. Сорау белән мөрәҗәгать итү мөмкинлеге

Әгәр мөрәҗәгать итүче, Татарстан Республикасының үз көченә кермәгән халыкара һәм тышкы икътисадый багланышлар турындагы килешүен Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килмәгәнлектән Татарстан Республикасында кертелергә һәм кулланылырга тиеш түгел дип санаса, аның конституциячеллеген тикшерүне сорый ала.».

39. 89 статьяда «140 статьясындагы икенче өлешендә» сүзләрен «109 статьясындагы өченче өлешендә» сүзләренә алмаштырырга.

40. 90 статьяда:

1 пунктта «, Татарстан Республикасы шартнамәләре белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

4 пунктта «дәүләт органнары» сүзләрен «Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясындагы өченче өлешендә күрсәтелгән органнар» сүзләренә алмаштырырга.

41. 91 статьяда:

91 статьяның беренче өлешендәге «Татарстан Республикасында дәүләт хакимияте» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары; Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белән җирле үзидарә органнары арасында; җирле үзидарә органнары арасында» сүзләренә алмаштырырга;

икенче өлештә «законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары» сүзләрен «Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларның» сүзләренә алмаштырырга.

42. 92 статьяның барлык тексты буенча тиешле килешләрдәге «дәүләт хакимияте» сүзләрен төшереп калдырырга.

43. 93 статьяда:

«даими комиссияләр, Татарстан Республикасы халык депутатларының биштән бере» сүзләрен «комитетлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының билгеләнгән санынннан биштән бере» сүзләренә алмаштырырга; «Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Парламент контроле комитеты,» һәм «һәм Татарстан Республикасы Югары суды» сүзләрен төшереп калдырырга.

44. 95 статьяда «даими комиссияләр һәм Парламент контроле комитеты» сүзләрен «комитетлар» сүзенә алмаштырырга.

45. 96 статьяда:

«, шулай ук әлеге мәсьәләне Татарстан Республикасы Конституция судының үз инициативасы буенча каравы» сүзләрен төшереп калдырырга;

«115 статьяның дүртенче өлешендә» сүзләрен «97 статьяның беренче өлешендәге 2 пунктында һәм икенче өлешенең икенче һәм өченче абзацларында» сүзләренә алмаштырырга.

46. 99 статьяның икенче өлешендә «Татарстан Республикасы Президентын Татарстан Республикасы Конституциясен бозган өчен вазыйфасыннан азат итү турында» сүзләрен «Татарстан Республикасы Президентына ышанычсызлык белдерү турында» сүзләренә алмаштырырга.

47. XIV һәм XV бүлекләренең исемнәрендә, шулай ук 100 статьяның икенче өлешендә, 101 статьяның беренче абзацында, 102-106 һәм 108 статьяларда «Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары» сүзләрен тиешле килешләрдә һәм саннарда «Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлар» сүзләренә алмаштырырга.

48. 100 статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы Конституция судына конституциячел хокукларның һәм ирекләрнең бозылуына карата шикаять белән Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, җирле үзидарә органнарының һәм аларның берләшмәләренең норматив хокукый актлары белән хокуклары һәм ирекләре бозылган гражданнар мөрәҗәгать итәргә хокуклы.».

49. 109 статьяда:

дүртенче өлештә «хезмәт турындагы законнар» сүзеннән соң «һәм судлар аппаратлары хезмәткәрләренең хокукый хәле турында норматив актлар» сүзләрен өстәргә;

бишенче өлештә «Татарстан Республикасы законнарында» сүзләрен «законнарда» сүзенә алмаштырырга.

**2 статья**. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы халык депутатлары һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советының даими комиссияләре әлеге Закон белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларына беркетелгән вәкаләтләрне үз вәкаләтләре чоры тәмамланганга кадәр гамәлгә ашыралар.

Татарстан Республикасы
Президенты — М.Ш.Шәймиев

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2003 елның 21 октябре
№ 44-ЗРТ

Исп.: тел.
C:\Leisan\Perevod\zakon\2003\kenst.doc